**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"25" ноябрь 2021 ел. № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-Фз номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Югары Шашы торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы авылы территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Югары Шашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чишмәне койма белән әйләндерү:

- төзелеш материаллары сатып алу, төзелеш эшләре, транспорт чыгымнар һәм хезмәтләр өчен түләү;

2) Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

-лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу,урнаштыру һәм хезмәтләр өчен түләү;

3) Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- авыл территориясен чистарту һәм хезмәтләр өчен түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Югары Шашы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Югары Шашы авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Сибгатуллин Д.Р..